СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь 2024ел № 125

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының«мөлкәткә салым турында»28.06.2022 ел, №62 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 30.10.2014 елның 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының «мөлкәткә салым турында» 28.06.2022 ел, №62 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктында. ", шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата " сүзләрен төшереп калдырырга.;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин